# КАРАР

**“08” ноябрь 2021 ел** **№ 2**

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Апаз авыл җирлеге Пөшәңгәр авылында халык җыены нәтиҗәләре турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1,56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2021 елның 8 ноябрендә түбәндәге мәсьәлә буенча үткәрелгән халык җыены нәтиҗәсе белән халык җыены йомгаклау беркетмәсе төзелде:

«Сез 2022 елда яшәү урыны буенча Арча муниципаль районы Апаз авыл җирлеге Пөшәңгәр авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә, түләү күләме 250 сум тәшкил иткән көндезге формада укучы студентлардан, 1нче группа инвалидлардан, 70 яшьтән узган гражданнардан тыш, 500 сум күләмендә үзара салым кертү һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү итү буенча түбәндәге эшләргә юнәлдерү белән килешәсезме:

- Чапаев урамының 1 йортыннан 2 йортына кадәр, В. Әһлиуллин урамының 1 йортыннан Чапаев урамының 42а йортына кадәр, Тау урамының 35а йортыннан В. Әһлиуллин урамының 43 йортына кадәр юл-урам челтәрен вак таш белән каплау;
- В. Әһлиуллин, Чапаев урамнарында автомобиль юлын тигезләү өчен вак таш җәю һәм Ø500 мм суүткәргеч торба урнаштыру:
- 1 данә янгын гидранты сатып алу һәм урнаштыру;
- Пөшәңгәр авылында су челтәрләрен ремонтлау;
- урамнарны яктырту челтәрләрен ремонтлау, шул исәптән яктырткычлар, лампалар, изоляцияләнгән чыбыклар, таймерлар, счетчиклар, автоматлар, җибәргечләр сатып алу һәм урнаштыру?

Аерым мәсьәләләр буенча экономия барлыкка килгән очракта, авыл җирлеге башкарма комитетына акчаны җыенда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итү өчен җибәрергә рөхсәт итәргә.

“ӘЙЕ” “КАРШЫ””

Халык җыены йомгаклау беркетмәсе нигезендә сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 284 кеше кертелгән, җыенда катнашучылар саны 148 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучылар тавышы түбәндәгечә бүленде:

"Әйе" позициясе өчен халык җыенында катнашкан 148 кеше тавыш бирде; “Каршы" позициясе өчен җыенда катнашкан 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Апаз авыл җирлеге Пөшәңгәр авылында халык җыенын булып узган дип танырга, халык җыены нәтиҗәләре дөрес.

2. «Сез 2022 елда яшәү урыны буенча Арча муниципаль районы Апаз авыл җирлеге Пөшәңгәр авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә, түләү күләме 250 сум тәшкил иткән көндезге формада укучы студентлардан, 1нче группа инвалидлардан, 70 яшьтән узган гражданнардан тыш, 500 сум күләмендә үзара салым кертү һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү итү буенча түбәндәге эшләргә юнәлдерү белән килешәсезме:

- Чапаев урамының 1 йортыннан 2 йортына кадәр, В. Әһлиуллин урамының 1 йортыннан Чапаев урамының 42а йортына кадәр, Тау урамының 35а йортыннан В. Әһлиуллин урамының 43 йортына кадәр юл-урам челтәрен вак таш белән каплау;

- В. Әһлиуллин, Чапаев урамнарында автомобиль юлын тигезләү өчен вак таш җәю һәм Ø500 мм суүткәргеч торба урнаштыру:

- 1 данә янгын гидранты сатып алу һәм урнаштыру;

- Пөшәңгәр авылында су челтәрләрен ремонтлау;

- урамнарны яктырту челтәрләрен ремонтлау, шул исәптән яктырткычлар, лампалар, изоляцияләнгән чыбыклар, таймерлар, счетчиклар, автоматлар, җибәргечләр сатып алу һәм урнаштыру?

Аерым мәсьәләләр буенча экономия барлыкка килгән очракта, авыл җирлеге башкарма комитетына акчаны җыенда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итү өчен җибәрергә рөхсәт итәргә.

“ӘЙЕ” “КАРШЫ””

мәсьәләсе буенча карар кабул ителгән дип танырга.

3. Әлеге карарны халык күп җыела торган урыннарда мәгълүмат стендларына ТР, Арча районы, Пөшәңгәр авылы, Чапаев урамы, 33 йорт, Чапаев урамы, 42А йорты адреслары буенча, интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Арча муниципаль районының рәсми сайтында http://arsk.tatarstan.ru веб-адресы буенча урнаштыру юлы белән игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы Рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Апаз авыл җирлеге башлыгы Р.Ф.Котдусов